Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге Кәкре Атау авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«12» ноябрь 2020 ел                                                                                    № 7

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 10 ноябрендә, 11 ноябрендә, 12 ноябрендә узган: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гайтән авыл җирлеге Кәкре Атау торак пункты территориясендә торучы, 1 гр инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, балигъ булган һәр кешедән 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Кәкре Атау торак пунктында су белән тәэмин итү чыганагын норматив таләпләр белән тәэмин итү буенча эшләр үткәрү.

Кәкре Атау торак пунктында янгын сүндерү гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру.

Кәкре Атау торак пунктында парк территориясен киртәләп алу өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтү» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 319 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 220 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 186 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 34 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге Кәкре Атау торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гайтән авыл җирлеге Кәкре Атау торак пункты территориясендә торучы, 1 гр инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, балигъ булган һәр кешедән 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

Кәкре Атау торак пунктында су белән тәэмин итү чыганагын норматив таләпләр белән тәэмин итү буенча эшләр үткәрү.

Кәкре Атау торак пунктында янгын сүндерү гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру.

Кәкре Атау торак пунктында парк территориясен киртәләп алу өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтү» мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Кәкре Атау торак пункты мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: Н.В.Авдеева

Гайтән авыл җирлеге башлыгы Н.В.Авдеева